СОВЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.14, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

Совет мәйданы, 14 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-11-33, факс (84366)3-01-33, 3-14-33. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**Арча район Советы**

# КАРАРЫ

« 28 » август 2026 ел № 73

**Арча район Советының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында**

“Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында” 2026 елның 20 февралендәге 23-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә һәм “Ачык хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” Федераль законның 32 статьясындагы 2 өлешенең 29 пунктындагы “д” пунктчасының үз көчен югалтуын тану нигезендә Арча район Советы карар кабул итте:

1. Арча район Советының түбәндәге карарларын үз көчен югалткан дип танырга:

- Арча район Советының 2015 елның 12 августындагы 348 номерлы карары белән расланган “Арча муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру тәртибе турында” нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында” 2020 елның 05 февралендәге 304 номерлы карары (2018 елның 24 апрелендәге 179 номерлы, 2019 елның 14 мартындагы 226 номерлы үзгәрешләр белән);

- “Арча муниципаль районы территориясендә Муниципаль торак контроле турында нигезләмәне раслау хакында” 2026 елның 28 апрелендәге 50 номерлы карары».

2. Әлеге карар 2026 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча район Советының законлылык, җәмәгать тәртибен саклау һәм җирле үзидарә буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Арча муниципаль районы башлыгы,
Арча район Советы рәисе А.Г.Хисаметдинов